ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.05.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1145**

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләп чыгару өчен Зеленодольск муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының 2022 елның икенче кварталына нормативны билгеләү турында

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» Дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән расланган, «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры хакының 2022 елның икенче кварталына торак сатып алуга яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 62 857 (алтмыш ике мең сигез йөз илле җиде) сум күләмендә билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 гыйнварындагы «Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләп чыгару өчен Зеленодольск муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының 2022 елның беренче кварталына нормативын билгеләү турында» 47 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарны контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев